СОВЕТ ДЮСЬМЕТЬЕВСКОГО СЕЛЬСКОГО ПОСЕЛЕНИЯ МАМАДЫШСКОГО МУНИЦИПАЛЬНОГО РАЙОНА РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН
ул.Молодежная, д.17, с. Дюсьметьево, Мамадышский район, Республика Татарстан, 422150

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ МАМАДЫШ МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫ ДҮСМӘТ АВЫЛ ҖИРЛЕГЕ СОВЕТЫ
Яшьләр ур., 17 нче йорт, Дүсмәт авылы, Мамадыш районы, Татарстан Республикасы,422150

тел.(факс): (85563) 2-55-19; e-mail: Dusm.Mam@tatar.ru, www:mamadysh.tatarstan.ru

Решение — Карар

15 ноябрь 2023 ел — 4-31

Дүсмәт авыл җирлеге Советының 2005 елның 30 декабрендәге “ Дүсмәт авыл җирлеге башкарма комитетын төзү турында” 1-5 номерлы карарына үзгәрешләр һәм өстәмәләр кертү хакында

Район прокуратурасының 2023 елның 17 октябрендәге 02-01-19-2023 номерлы тәкъдимен карап, «Табигый дәвалау ресурслары, дәвалау-савыктыру урыннары һәм курортлар турында» Федераль законга, Россия Федерациясенең аерым закон актларына үзгәрешләр кертү һәм Россия Федерациясе закон актларының аерым нигезләмәләренең үз көчләрен югалтуын тану хакында» 2023 елның 4 августындагы 469-ФЗ номерлы, «Россия Федерациясендә җирле үзидарә оештыруның гомуми принциплары турында» 2003 елның 06 октябрендәге 131-ФЗ номерлы Федераль законнар, Татарстан Республикасы Мамадыш муниципаль районы «Дүсмәт авыл җирлеге» муниципаль берәмлеге Уставы нигезендә Мамадыш муниципаль районы Дүсмәт авыл җирлеге Советы КАРАР КАБУЛ ИТТЕ:

1. Дүсмәт авыл җирлеге Советының 2005 елның 30 декабрендәге «Дүсмәт авыл җирлеге башкарма комитетын төзү турында» 1-5 номерлы карарына түбәндәге үзгәрешләрне һәм өстәмәләрне кертергә:

1.1. Нигезләмәнең 3.2 пунктындагы 28 нче абзацында “торак пункт территориясендә җирле әһәмияттәге дәвалау-сәламәтләндерү урыннарын һәм курортларны булдыру, үстерү һәм саклауны тәэмин итү, шулай ук " дигән сүзләрне төшереп калдырырыга.

2. Әлеге карарның 1.1 пункты 2024 елның 1 сентябреннән үз көченә керә дип билгеләргә.

3. Әлеге карарны авыл җирлегенең мәгълүмати стендларында, Мамадыш муниципаль районының mamadysh.tatarstan.ru рәсми сайтында, Татарстан Республикасы хокукый мәгълүматының рәсми порталында (pravo.tatarstan.ru) урнаштыру юлы белән игълан итәргә.

4. Әлеге карарның үтәлешен контрольдә тотуны Мамадыш муниципаль районының Дүсмәт авыл җирлеге башлыгы Р.М. Ефимовка йөкләргә.

Мамадыш муниципаль районы
Дүсмәт авыл җирлеге Советы рәисе,
җирлекбашлыгы /Р.М.Ефимов/

СОВЕТ ДЮСЬМЕТЬЕВСКОГО СЕЛЬСКОГО ПОСЕЛЕНИЯ